ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
УРАЗБАХТИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д.1А, с. Уразбахтино,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422155

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ УРАЗБАХТЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Совет ур., 1А йорт, Уразбахты авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422155

тел.(факс): (85563) 2-86-36; e-mail: UrBah.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

**КАРАР** **Постановление**

17.09.2018 № 18

Референдум уздыру инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясының 2 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, "Җирле референдум турында» 2004 ел, 23 март, 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Уразбахты авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлеге Башкарма комитеты К А Р А Р БИРӘ:

1.Түбәндәге сораулар буенча җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2019 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

1. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмиятле автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру;

- Уразбахты торак пунктында Галләм урамы, Җиңү урамы, Ленин урамы юлларын вакташ җәеп ремонтлау;
- авыл җирлегенә караучы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту.

« ӘЙЕ » « ЮК »

2. Әлеге карарны муниципаль берәмлек мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлеге башлыгы Р.Г.Шәйхетдиновка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Уразбахты авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Шәйхетдинов Р.Г.